УДК 9-05

*Р.Ә. Абзалина*

# КҮҢЕЛ МАТУРЛЫГЫН СУРӘТЛӘРЛЕК ПУМАЛАЛАР БАРМЫ ДӨНЬЯДА?.. (К. Насыйри портретын ясау тарихы)

Статья посвящена истории создания общеизвестного портрета ученого-просветителя Каюма Насыри (1825–1902), ставшего хрестоматийным. Автор, опираясь на воспоминания современников К. Насыри, повествует, как последующие поколения ученых и художников старались воссоздать образ ученого-просветителя и энциклопедиста, который никогда не фотографировался. Каждое воспоминание, оставленное современниками о нем, говорит об их собственной степени возможного понятия его учености и воспитанности, самого главного его намерения – на что суждено было ему посвятить всю свою жизнь. В воспоминаниях современников Каюма Насыри личный характер и творческое лицо раскрывается по разному: если одни не очень приветствовали его малословность в общении с людьми, особое отношение к своему внешнему виду, то другие, особенно земляки, почти каждую черту его характера, также образ его жизни считали примером, хотя и не досягаемым для всех желающих стать праведными как он. Они прекрасно понимали, что каждое его деяние идет от его стремления к довольству Всевышнего, для пользы общества, не забывая о своем статусе в обоих мирах. Земляки лучше всех понимали его ум, мудрость и желание просветить свой народ полезными и нужными знаниями, накопленными восточно-западным опытом в мировой цивилизации. Он сам добился этого, и мы – его потенциальные последователи хотя и очень медленно идем к пониманию его.

**Ключевые слова:** Каюм Насыри, портрет, современники-земляки, воспоминания, графика, художник Байназар Альменов, татарская культура.

The article is devoted to the history of the creation of the well-known portrait of the enlightenment scientist Kayum Nasyri (1825–1902), which became a textbook. The author, based on the memoirs of K. Nasyri’s contemporaries, tells how subsequent generations of scientists and artists tried to recreate the image of a scientist, educator and encyclopedist who had never been photographed. Every memory left by his contemporaries speaks about their own degree of possible understanding of his scholarship and upbringing, his most important intention – what he was destined to devote his whole life to. In the memoirs of Kayum Nasyri’s contemporaries his personal character and creative personality are revealed in different ways: if some did not really welcome his laconicism in communication with people, his special attitude to his appearance, then others, especially his fellow countrymen, considered almost every feature of his character, as well as his way of life, an example, although not attainable for all who wish to become righteous like him. They understood perfectly well that each of his actions came from his desire to please God for the benefit of society, not forgetting about his status in both worlds. His fellow countrymen understood better than anyone his mind, wisdom and desire to enlighten his people with useful and necessary knowledge, accumulated by the East-West experience in world civilization. He himself achieved this and we – his potential followers, although very slowly move towards understanding him.

**Keywords:** Kayum Nasyri, portrait, contemporaries, fellow countrymen, memories, graphics, artist Baynazar Almenov, tatar culture.

Әлеге мәкалә мәгърифәтче, галим Каюм Насыйриның (1825–1902) киң җәмәгатьчелеккә билгеле, популяр портретын ясау тарихына багышлана. Автор галимнәр һәм рәссамнарның, К. Насыйриның замандашлары истәлекләренә таянып, аның образын тудырырга тырышулары турында сөйли.

Ислам дине кануннары мөселманнарга кеше һәм хайван-җәнлек сурәтләрен өй-мәктәп диварларына элергә рөхсәт итми. Халыкка ул андый йорттан фәрештәләр кача дип, бик катгый тәртиптә кереп калган. Фото мәсьәләсендә дә шулайрак. Ләкин күренекле мөселман татар галимнәре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддиновның фотопортретлары булган. Ш. Мәрҗани үз портретын инглиз энциклопедиясенә сораткач ясаткан. Р. Фәхреддиновның балалары белән эшләнгән гаилә фотолары бар. Ул диварга элү өчен түгел, истәлек итеп альбомнарда сакларга дип фәтва калдырган.

Күренекле татар мәгърифәтчесе, педагог, галим-энциклопедист Каюм Насыйри бер тапкыр да фотога төшмәгән. Ләкин менә тууына 200 еллап вакыт үткәннән соң, нигездә, рәссам Б. Әлминов ясаган портрет аша аның тышкы кыяфәте, холкы, галимлеге белән бергә үрелеп, бик анык булып күз алдына килеп баса: озынча чандыр йөз, үзе белгәннәрне башкаларга белдерү тактикасын һәм стратегиясен уйлап торган тәвәккәл уйчан күзләр, сүзләрен үлчәп кенә чыгара алган иреннәр, киң маңгай. Истәлекләрендә чәчләрен бераз озынчарак йөртә дип язылса да, гомердә дә яланбаш итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирмәгән, үзенә бик тә килешле кырпулы бүрек. Заманына күрә бик фасонлы, буйлы ак күлмәк һәм урта озынлыктагы тездән бераз түбән җилән яки тун.

Совет чорында Каюм Насыйриның иң беренче портретын аның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итәргә җыенганда Госман Арсланов дигән рәссам ясаган була. Истәлекләр буенча бик тә ачык итеп күз алдына китерергә ярдәм иткән бу портрет голәманы канәгатьләндереп бетерми. 1944–1945 елларда инде аның 120 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә татар Ломоносовының кыяфәтен бераз тантаналырак итеп күзаллау ихтыяҗы яңадан баш калкыта. Бу эшне күренекле галим, Казандагы Тел, әдәбият, тарих институты директоры Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин рәссам, график Байназар Мостафа улы Әлминовка махсус заказ белән ясата.

1944 ел, Каюм Насыйриның 1945 елда үткәреләсе 120 еллыгына әзерлек вакыты. Әле ул вакытта Казанда Каюм Насыйрины хәтерләгән, аннан дәресләр алган шәкерт-бабайлар исән. Бу эшләрдә Мөхәммәт Гайнуллин Б. Әлминовка ярдәмче консультант итеп язучы Мөхәммәт Галине (1893–1952) билгели. М. Гали белән Б. Әлминов, икәүләп, Казан буйлап Каюм Насыйрида укыган бер бабайны эзләп табып, аның белән бик озак сөйләшкәч, «Әлеге карт рәсемгә төшәргә риза булмаса да, үзенең кыяфәте белән минем күз алдына килә башлаган Каюм Насыйри образын байтак кына көчәйтте», – дип искә ала үзенең «Каюм Насыйриның портреты ничек туды» дигән мәкаләсендә

Б. Әлминов. «Шуннан соң мин эшкә керештем. 5–6 вариант ясагач, портретны тотып, Мөхәммәт абый белән теге Каюм Насыйрида укыган бабайга яңадан бардык. Рәсемнәрне күрсәттек, кайсы вариантның кай ягы белән Каюм Насыйрига якынрак булуын сораштык. Шуннан соң кайтып, мин тагын бер портрет ясадым. Монысын да күрсәттек. Картыбыз хуп күрде: «Нәкъ үзе», – диде. Әйткән фикерен раслатыр өчен булса кирәк, ул бездән рәсемне үзенең элекке сабакташына күрсәтеп алырга киңәш итте. Без ... бабайны эзләп таптык. Танышып, хәл-әхвәл сорашканнан соң, аңа соңгы портретны күрсәттек һәм аның кем икәнлеген әйтеп бирүен үтендек. Карт шунда ук:

– Бу безне укыткан Каюм хәлфә, – диде.

Безгә шул гына кирәк иде дә.

Мөхәммәт ага Гали институтның бер утырышында шушы портрет вакыйгасын сөйләп бирде һәм ул гыйльми советта расланды. Сезнең күз алдыгыздагы портрет шулай туды. Мин шуннан соң да Каюм Насыйриның портретын берничә вариантта ясадым» [2].

Якташы буларак та һәм туган авылым Олы Ачасырда 1982–1997 елларда Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография музеен төзегәндә дә минем өчен бу мәсьәлә бик актуаль булып, Б. Әлминов фотога төшмәгән Габделкаюм Габденнасыйр аганың мондый эчтән нурлы голәма портретын ничек ясый алды икән, дигән уй башымнан чыкмады.

«Совет мәктәбе» журналының 1975 елгы өченче санында басылып чыккан мәкалә бу мәсьәләгә тулы ачыклык кerткән булыр иде дә бит, ләкин мин аның белән таныш булмыйча, үземчә мәгълүмат эзләвемне дәвам иттем. Каюм Насыйриның фикердәш имамнары Гайнеддин (1810 елгы) һәм Сәгъдеддин Таһириларның (1820 елгы) ага-энеләре Гыйрфанеддин Сәгъдеддин улының (1854–1902) оныгы Габбаз Габделхәбир улы аша миңа килеп ирешкән риваятьләрнең берсе буенча: «1945 ел башында Каюм Насыйриның 120 еллык юбилеена әзерләнеп йөргән вакыт, Шырданга 6 рәссам кайтып төшә. Каюм Насыйриның нindирәк кыяфәттә булуын авылдашларыннан сорашып, алар һәммәсе К. Насыйри портретының үз вариантларын ясыйлар. Шулар арасыннан авыл кешеләре сайлап, менә бу Каюм Насыйрига охшаш дигәне Б. Әлминовныкы булып чыккан». Менә монысы инде – күрше авыл халкы хатирәсе.

Чынлап та, 1945 елның гыйнвар-февраль аенда Югары Шырданга Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре экспедиция белән кайталар. Галимне күргән-белгән кешеләрдән истәлекләр яздырып, авыл күренешләрен һәм кешеләрне фотога төшереп, соңыннан истәлекләрне бастырып та чыгаралар. Бу материаллар Мирасханәдә 11 фонд, 3 тасвирлама, 7 саклау берәмлеге булып теркәлгән. Хәмит Ярми көндәлегендә: «Югары Шырдан авылында без Ибәтуллин Әхмәдулла абзыйда тордык, аның улы Абдулла Паратскийда заводта эшли иде», – дип язып куйган [8].

Бу вакыт Югары Шырданга кайткан галимнәр арасында Хәмит Ярми, Гомәр Хисаметдинов, Халидә Гатина бар, рәссамнар турында истәлек теркәлмәгән.

Каюм Насыйри турында истәлекләрендә Габдулла бине Таҗетдин әл Кәчмәри аның тышкы кыяфәтен болай тасвирлап калдыра: «Габделкаюм әл-Насыйри әфәнде урта буйлы, зур башлы булып, чәчен җитүрәк йөртә иде. Борын вә авыз килешле, төсе ак түгел, бәлки богдай төсендәрәк, йөзе ачык түгел, караңгырак иде. Күзләре зәгыйфь булудан язуны күзенә бик якын китереп карый иде. Мыекны җитүрәк йөртә. Сакалы сирәк булып, артык озын җибәрми иде. Йөрүе әкрен, алдына карап турырак басып йөри. Хәлен белгән адәмнәр, элек русча укып йөргән вакытларында европачарак та киенеп йөргән, диләр» [5].

Габдулла бине Таҗетдин әл Кәчмәри Каюм Насыйридан: «Миңа рәсемегезне һәдия кылсагыз, тәзкирә – ядкәр булыр иде, дидем. Җавабында: “Рәсем алдыртмадым”, – диде, бәлки “Алай булса, сезгә менә тәзкирә”, – дип, бәгъзысы хадис, бәгъзысы хәкимнәр сүзеннән гыйбарәт сигез кисәк үз каләме илә язылган язуын бирде» [5].

Шул ук җыентыкта Кукмара районы Пычак авылында яшәгән Мөхәммәтханиф Мозаффари Каюм Насыйри турында атасы Мөхәммәтҗан Мозаффаридан ишеткән истәлеге урын ала: «Мин Шиһап хәзрәт мәдрәсәсендә шәкерт вакытымда Габделкаюм әфәнде белән күп катыштым. Аның үз сүзенә караганда, уң күзенә кызамык илә ак төшкән вә сул күзе тумыштан сукыр булган. Уң күзе яхшы күрә иде. Ләкин даим күк күзлек истигъмаль кылды. Аягында савырлы читеккәвеш, өстендә ак көмеш тамгалы постау казаки, борынгы әйләнмә якасыз зәңгәр постау чикмән, зәңгәр постау чалбары кәвеш йөзенә төшеп тора иде. Башында бер карыш киңлегендә камчат бүрек, кулында җәйләрдә зонтик, кышын кыска таяк тота, төлке тамак толып вә яхшы туннары да бар иде. Шырданда утыз-кырык умартасы булган. Умартасы кырык баштан артмады, утыздан кимемәде дип сөйли иде. Йөргәндә алдына гына карап йөри, һичкемнең кибетенә кереп сөйләшеп утырмый, урамда да сөйләшеп тормый. Сөйләшергә теләүче булса: “Фатирыма бар, шунда сөйләшербез”, – дия иде. Каһкаһә белән көлгәнен ишетмәдем, тәбәсеме (елмаюы) дә аз булгандыр.

Сурәт алдыру мәсьәләсенә килсәк, Каюм әфәнденең аңа хилаф булмавы беленә. Ул үзе сурәтләр тоткан. Бервакыт эткәмезгә Шиһап хәзрәт сурәтен күрсәткән. Ләкин инкяр галәмәте бер дә беленмәгән» [6].

Гомумән, Каюм Насыйри тарикать әдәпләрен нык белгән генә түгел, ул аларны тоткан: үзенә кагылмаган эшкә кысылу һәм мөгамәлә күрсәтүне кирәк санамаган. Каюм Насыйриның үз вакытында алдырган фото һәм рәсемен аның хакында язучылар да күрмәгәннәр һәм безнең дә күргәнебез юк әле. Әдәбият кабинетларында урын алган һәм хрестоматия-дәреслекләргә урнаштырылган рәсем аны күрүчеләрнең истәлекләреннән чыгып кына эшләнгән. Гомеренең соңгы елларында аның рәсемен сорап килүчеләр булган. Ләкин Каюм

Насыйри аларга: «Рәсем алдырганым юк», ә алдырып бирүен сораучыларга: «Ач вакытта да хәлемне сорамадылар, хәзер соң инде», – дигән мәгънәдәрәк җавап биргән [1].

Аның бу турыда бәхәс корып, сөйләшеп торып, вакыт әрәм итәсе килмәгәнлегеннән дип тә аңларга кирәк.

Каюм Насыйри гомеренең һәр минутының кадерен белә. Малны да таба, тота белә, аны тиешле урыннарга тарата да белә. Васыятьләрендә үзе өчен хаҗга барасы кешеләргә хәтле язып калдыра. Кыз туганы, ата-ана хакын хаклый.

Шулай да ул үзенең төп эшен татар фәнен аякка бастыруда, кешегә файдалы гыйлемнәрне аңлаешлы татар телендә татар кешесенә язып, аңлатып бирүдә күрә. Ул бу фәннәрне Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәгърифәтеннән яңарта. Аның барлык хезмәтләре «Менә күрегез, мин нинди кәттә галим», – диюдән түгел, үзе белгәннәрне белмәгәннәргә белдерү, кешеләрнең көнкүреш ихтыяҗларын җиңеләйтү, файдалы итү өчен башкарылган.

«Каюм Насыйри 1865 елда Казанның ямщик Мөсәгыйть кызына өйләнгән булган. Бер елдан соң хатыны бала хастасыннан үлә. Шуннан соң Насыйри ялгыз, гаиләсез яши», – диелгән галимнең тууына 120 ел тулу уңаеннан үткәрелгән гыйльми сессия материалларында [1].

Югарыда бер искә алынган Габбаз абый Хәбировтан (1913–1995) килеп ирешкән риваять буенча, ул яңадан өйләнгән була. Ләкин озак яши алмый. Хатынның әти-әнисен, бар туганнарын чакырып, мәҗлес җыя, кунак иткәч: «Кызыгыз бик күркәм, бер сүзем юк. Ләкин мин гаилә тормышы өчен яратылмаганмын ахры. Фән белән мавыгып, үземнең гаилә кешесе икәнен бөтенләй онытам. Кызыгызны алып кайтып, ышанычлы кешегә урнаштырыгыз», – дип кайтарып җибәргән», ди.

Каюм Насыйри мәгърифәт өчен дөнья ләззәтләреннән ваз кичкән дип әйтү дөрес түгел. «Мине Алла китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», – ул бу эшне чын күңелдән үзе дә ләззәт алып башкара белгән [7].

Каюм Насыйри турында истәлек калдырган бик күп кешеләр аның янына төрле киңәшләр, бигрәк тә авыл муллалары төрле авырулардан дәва сорап килә торган булганнар. Ул һәр кешене кабул итә, башта хәлен сорый, чәй янында булса, янына утыртып, чәй эчәргә тәкъдим итә. Зыя Бәхтияровның астрономия дәреслеген язуын бик хуплап, китап табып биреп ярдәм итә. Киңәш, ярдәм сорап килгән кешеләрнең берсен дә кире бормый. Купшы сүзләр белән түгел, туптуры кыска итеп аңлатып бирә. Тар фикерлелекне бер дә яратмый: «Дөньяда шуннан башка бернәрсә дә юк дип беләсеңме әллә?» – ди ул һәрвакыт бер нәрсә турында сорап йөдәткән кешеләргә.

Хатип Алишев дигән кеше аның элеккеге Мәрҗани, хәзер Каюм Насыйри урамында торган йортын хәтерләп болай яза: «Ишектән кергәч тә, аның өенең алгы ягында һөнәр кирәк-яраклары (зур гына

пыяла савыт, бер станок һ. б. нәрсәләр) күзгә ташлана. Уртада мич, мич яныннан ишексез генә бүлмә корылган, мич артыннан почмакка кереп китә. Анда стенага кара такта эленгән. Шунда берничә бала укыйлар. Бүлмә янында тәбәнәк аяклы өстәл. Утыргычлар юк. Өстәл өстендә язылган кәгазьләр, китаплар, глобус, җәзбәләр һәм башка геометрия кораллары бар. Мин аннан бер айлап чамасы геометрия укыдым. Шул вакытта аның өстәлендәге бу нәрсәләр турында мин аннан сораша идем. Ул миңа аңлатып сөйли иде. Шул ук бүлмәгә эленгән бер кием яңа чабата тора. Ул аны үзем тукыдым дия торган иде. Ул күптөрле һөнәрләр, гыйльми мәсьәләләр турында сөйләргә ярата иде. Электрик белән нәрсә көмешләү, көзге ясау, кимьяви (химический) нәрсәләр һәм башкалар турында сөйли иде. – Хатыннарның икмәк пешерү, икмәкне изү, салу эшләре дә кимья гыйлеме белән эшләнә», – ди торган иде.

– Һади балалар өчен төзегән әлифбасын миннән күреп төзеде, – дип сөйләгәне исемдә.

Мәдрәсәләрдә хисап, тарих, һәндәсә һәм һәйәт (астрономия) кебек фәннәр укылмауга бик пошынып сөйли иде. «Укытмыйлар бит шул кирәкле фәннәрне», – ди торган иде.

Аны Печән базарында «Сукыр Каюм» дип йөртәләр иде. Мин аның әсәрләрен укып, бик күп файдаландым.

Каюм Насыйриның юбилее булачагы турындагы хәбәрне ишеткәч, бер гарәп шагыйренең: «Күзләр олы йолдызларны кечкенә күрәләр. Ләкин аның гөнаһысы йолдызда түгел – күз кабагында» [1], дигән сүзләре искә төшә. Ничә буын Кизләү ишаннары, аннан алдарак Тау ягы – Тәтеш имамнары дәвамчысы Хатип Алишев-Әлмәти сүзләренә өтер дә өстисе килми. Ләкин хәзерге көнгә кадәр чын йолдызлар да, аларны адекват күрә алган күзләр дә, сирәк булса да, туа тора – моңа ышанасы, омтыласы килә...

Каюм Насыйри – татар мәдәниятендә галимнәрнең җанлы әйберләрне сурәтләүгә традицион карашын катгый рәвештә үзгәрешсез дәвам иткән мөселман галиме. Заманының кая таба барганын чамаласа да, ул моңа бик тыныч караган һәм нык позициядә кала белгән. Бик күп сорауларга хикмәти Хуҗа Насреддин кебек җавап биргән: «Нигә туныңны тышка әйләндереп йонлы ягын өскә куеп киден?» – дигәнгә дә: «Җәнлекләр табигатьтә шулай йөри, минем табигатькә каршы барасым килми», – ди. Гәрчә моңа күнекмәгән кешегә туннарның яңа мода «доха» дигәне дә барлыгын аңлатып торуны файдасыз саный. Кеше турында фикер йөрткәндә, аның тышкы кыяфәте түгел, ә эчке дөньясы – күркәм холкы, белеме-зирәклеге мөһим, ди. Күркәм холык йөзгә якты нур булып эчтән бәреп чыга, үзе һәм үз чорына гына түгел, тирә-юньгә һәм вакытлар кичеп үз эшен эшләп мәгърифәт таратуын дәвам итә. Каюм Насыйри портреты – шуның бер мисалы.

**Кулланылган чыганаклар һәм әдәбият**

1. *Алишев Хатип Әлмәти.* Хатип Алишев истәлекләре. Каюм Насыйри (1825–1945). Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 141.

2. *Әлминов Б.М.* Каюм Насыйриның портреты ничек туды // Совет мәктәбе. 1975. № 3. Б. 62.

3. *Гали М.* Зыя Бәхтияров истәлекләре. Каюм Насыйри (1825–1945). Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 140.

4. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге. К. Насыйри фонды: 11 ф., 3 тасв.

5. *Кәчмәри Г.Т.* Габделкаюм әл-Насыйри // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 65.

6. *Мозаффар М.* Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 62–63.

7. *Хуҗаши әл Насреддин әл Хуҗаши.* Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри әфәнде белән мөсахабә // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 73.

8. *Ярми Х.* Ю. Шырданда язылган көндәлек. 1945 ел. 6 январь – 11 февраль // ТР ММ. В 20320. 18 б.

***Абзалина Рәмзия Әсрареддин кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

***Абзалина Рамзия Асраровна,***
*старший научный сотрудник Национального музея*
*Республики Татарстан*
*globus54@list.ru*